ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПО ТАРИФАМ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

01.12.2017 Казан ш. № 4-3/г

Татарстан Республикасында Газлаштыру программасын финанслау өчен «Газпром трансгаз Казань» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең газ бүлү челтәрләре буенча газ транспортлау хезмәтләренә тарифларга 2018 ел өчен махсус өстәмә бәя күләмнәрен билгеләү хакында

«Россия Федерациясендә газ белән тәэмин итү турында» 1999 елның 31 мартындагы 69-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Газлаштыру программаларын финанслау өчен газ бүлү оешмалары тарафыннан газ транспортлау тарифларына махсус өстәмә бәяләр билгеләү тәртибе турында» 2001 елның 3 маендагы 335 номерлы карары, Федераль тарифлар хезмәтенең «Газлаштыру программаларын финанслау өчен газ бүлү оешмалары тарафыннан газ транспортлау тарифларына махсус өстәмә бәяләр күләмен билгеләү методикасын раслау турында» 2011 елның 21 июнендәге 154-э/4 номерлы боерыгы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмә нигезендә Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасында Газлаштыру программасын финанслау өчен «Газпром трансгаз Казань» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең газ бүлү челтәрләре буенча газ транспортлау хезмәтләренә тарифларга кулланучыларның барлык төркемнәре өчен (халыктан кала) 2018 елның 1 гыйнварыннан 2018 елның 31 декабренә кадәр шушы карар кушымтасына туры китереп, календарь буенча бүленгән махсус өстәмә бәя күләмнәрен билгеләргә.

2. Бу карар рәсми басылып чыккан көненнән башлап 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәис М.Р.Зарипов

Татарстан Республикасы
Тарифлар буенча дәүләт
комитетының 01.12.2017
№ 4-3/г карарына кушымта

Татарстан Республикасында Газлаштыру программасын финанслау өчен «Газпром трансгаз Казань» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең газ бүлү челтәрләре буенча газ транспортлау хезмәтләренә тарифларга 2018 ел өчен календарь буенча бүленгән махсус өстәмә бәя күләмнәре

| Татарстан Республикасы газ бүлү оешмасының аталышы | Ел | Махсус өстәмә бәя күләме, 1000 куб. м. өчен сум (НДС исәпкә алмыйча) |
|---|---|---|
| «Газпром трансгаз Казань» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте | 01.01.2018 башлап 30.06.2018 кадәр | 44,17 |
| | 01.07.2018 башлап 31.12.2018 кадәр | 59,34 |

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының тариф чишелешләрен кабул итүне оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге